СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗƏЛƏ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 июнь 2018 ел г.Мензелинск № 2

**Каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һəм күмү буенча халыкка күрсəтелə торган хезмəтлəргə тарифлар турында**

Россия Федерациясенең 29.12.2004 кабул ителгəн №188-ФЗ Торак кодексы, 30.12.2004 кабул ителгəн "Коммуналь комплекс оешмаларының тарифын җайга салу нигезлəре турында"гы №210-ФЗ Федераль Закон, Россия Федерациясе Хөкүмəтенең 14.07.2008 елда кабул ителгəн "Коммуналь комплекс оешмаларының эшчəнлеге өлкəсендə тарифларны, өстəмəлəрне һəм чик индексын җайга салу тəртибе һəм бəя хасил итү нигезлəре турында"гы № 520 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.12.2016 елда кабул ителгəн "Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыкларын туплау нормативларын раслау турында"гы № 922 карары, 1998 елның 24 июнендə кабул ителгəн "Җитештерү калдыклары һəм куллану турында"гы № 89-ФЗ федераль Законы нигезендə

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2018 елның 1 июленнəн күпфатирлы йорт белəн идарə итү ысулын сайламаган торак биналар хуҗалары өчен торак бинасын карап тотуга һəм муниципаль торак фондының торак биналарны наемга алу килешүлəре һəм социаль наем килешүлəре буенча торак биналар алучылар өчен торак биналарны карап тотуга IV-V класслы куркыныч тудыручы каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һəм күмү өчен тарифларны билгелəргə һəм гамəлгə кертергə:

**- Минзəлə шəһəр халкы өчен** – айга бер кешедəн, НДСны исəплəмичə, - 45, 05 сум (нормативлар нигезендə елга каты көнкүреш калдыклары күлəме – 1,1 куб.м)

**-Минзəлə муниципаль районының авыл җирлеклəрендə яшəүчелəр өчен** - айга бер кешедəн, НДСны исəплəмичə, - 55, 05 сум (нормативлар нигезендə елга каты көнкүреш калдыклары күлəме – 1,1 куб.м)

2. Татарстан Республикасы Минзəлə муниципаль район Советының 15.12.2017 елда кабул ителгəн "2018 елда халыкка күрсəтелə торган торак-коммуналь хезмəтлəргə тарифлар турында"гы Карары көчен югалткан дип санарга.

3. Гамәлдәге карар Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет челтәрендә куелырга тиеш.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Ягафаровка, Минзәлә муниципаль район Советының икътисад, бюджет һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясе рәисе Р.Ш.Газизяновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район башлыгы А.Ф.Салахов